ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11.2024 ел Баулы шәһәре №159

2025 елга Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законының 99 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендәге 1 бүлекнең 11 пункты, «Баулы муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2007 елның 11 декабрендәге 201 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2025 елга Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнарны расларга.

2. Баулы муниципаль районы финанс-бюджет палатасына, мәгариф оешмаларын, әлеге карарның 1 пункты белән расланган, мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 7 ноябрендәге
159 номерлы карары белән

РАСЛАНГАННАР

2025 елда Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләрне тотуга
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Гомуми белем бирү оешмасының төре | Территориаль дислокациясе | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 118 316,00 |
| | авыл җирлеге | 119 559,00 |
| Гомуми белем бирү мәктәп-интернаты | шәһәр җирлеге | 177 385,00 |
| | авыл җирлеге | 181 658,00 |